**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Карата авыл**
**җирлеге**
**башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Старохурадинского**
**сельского поселения**
**Алькеевского муниципального**
**района РТ**

Адрес: 422898, РТ, Әлки районы Сиктәрмә авылы, Мәктеп ур., 15й Тел/факс: (84346) 73-4-03

Адрес: 422898, РТ, Алькеевский район с. Сиктерме Школьная, д.15 тел/факс: ( 84346) 73-4-03

КАРАР

13 октябрь 2025 № 52

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы 20-нче номерлы карарына «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Иске Карата авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, аның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 елның 2314-нче карары «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» (14 март 2024 ел үзгәрешләр кертеп)" нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 22 мартындагы 20-нче номерлы Карарының «Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге территориясендә терекөмешле эшкәртелгән лампалар туплану урыннары турында" 4 пунктынын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлеге Җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында (стойкаларында) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә».

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның «30» июлендәге 44-нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында: http://alkeevskiy.tatarstan.ru/ урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Карата авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
вакытлыча вазыйфаларын башкаручы Т.В.Муллина